**«РАСЛЫЙМ»**

**Татарстан Республикасы**

**Премьер-министры**

**урынбасары – министр**

**_____________ Р.Т. Борһанов**

**«23» гыйнвар 2020 нче ел**

**Төп гомуми белем бирү программалары буенча төп дәүләт имтиханы (ТДИ) формасында дәүләт йомгаклау аттестациясе**

**2020 нче елда ИНФОРМАТИКАдан төп дәүләт имтиханын үткәрү өчен контроль үлчәү материалларының демонстрация варианты**

"ФЕДЕРАЛЬНЫЙ ИНСТИТУТ ПЕДАГОГИЧЕСКИХ ИЗМЕРЕНИЙ" Федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе тарафыннан әзерләнгән

# ИНФОРМАТИКАдан төп дәүләт имтиханы

2020 нче елгы төп дәүләт имтиханының ИНФОРМАТИКАдан контроль үлчәү материалларының демонстрация вариантына аңлатмалар

2020 нче елгы демонстрация варианты белән танышкан вакытта, демонстрация вариантына кертелгән биремнәрнең КҮМ вариантлары ярдәмендә 2020 нче елда тикшерелә торган эчтәлек элементларының барысын да чагылдырмауларын истә тотарга кирәк. 2020 нче елгы имтиханда контрольгә алына торган эчтәлек элементларының тулы исемлеге www.fipi.ru сайтында урнаштырылган төп дәүләт имтиханын үткәрү өчен укучыларны әзерләү дәрәҗәсенә карата эчтәлек һәм таләпләр элементлары Кодификаторында бирелгән.

Демонстрация варианты имтиханда катнашучыларга һәм киң катлам җәмәгатьчелеккә имтихан эшенең структурасы, биремнәр саны һәм формасы, аларның катлаулылык дәрәҗәсе турында күзаллау булдыру максатыннан тәкъдим ителә. Имтихан эшенең демонстрация вариантына кертелгән, киңәйтелгән җаваплы биремнәр башкаруны бәяләү өчен тәкъдим ителгән критерийлар әлеге биремнәрне башкарып чыгу өчен таләпләр турында күзаллау булдырырга ярдәм итәрләр.

Әлеге мәгълүматлар чыгарылыш сыйныф укучыларына 2020 нче елда информатикадан имтихан тапшыруга әзерлек стратегиясен булдырырга мөмкинлек бирәләр.

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

**2020 нче елгы төп дәүләт имтиханының ИНФОРМАТИКАдан контроль үлчәү материалларының демонстрация варианты**

**Эшне башкару өчен инструкция**

Имтихан эше 2 өлешкә бүленгән, һәр өлеш 15 биремнән тора. Беренче өлеш кыска җаваплы 10 биремне, икенче өлеш компьютерда эшләүне таләп иткән 5 биремне үз эченә ала.

Информатикадан имтихан эшен башкарып чыгу өчен барлыгы 2 сәгать 30 минут (150 минут) бирелә. Сез биремнәрне башкаруга вакытны үзегез билгели аласыз, әмма 1 нче өлеш биремнәрен башкаруга тәкъдим ителгән вакыт – 30 минут, 2 нче өлеш биремнәрен башкаруга тәкъдим ителгән вакыт – 2 сәгать (120 минут).

1-12 нче биремнәргә җаваплар сан, сүз, хәрефләр яисә цифрлар эзлеклелеге рәвешендә языла. Җавапны эш текстындагы җавап кырына языгыз, аннары 1 нче номерлы җаваплар бланкына күчерегез.

13-15 нче биремнәрнең һәрберсенең башкарылу нәтиҗәсе аерым бер файлдан гыйбарәт. Файл форматын, аның исемен һәм саклау өчен каталог адресын Сезгә имтиханны оештыручылар хәбәр итәчәк.

Барлык бланклар да ачык кара төстәге кара белән тутырылалар. Гель яисә капилляр каләм (ручка) кулланырга рөхсәт ителә.

Биремнәрне үтәгәндә караламадан файдаланырга мөмкин. Караламадагы һәм контроль үлчәү материаллары текстындагы язмалар эшне бәяләгәндә исәпкә алынмый.

Башкарылган биремнәр өчен җыйган балларыгыз аннары бергә кушыла. Күбрәк биремнәр башкарырга һәм күбрәк баллар җыярга тырышыгыз.

Эшегезне тәмамлаганнан соң 1 нче номерлы җаваплар бланкындагы һәр биремгә җавапның дөрес номер белән язылуын тикшереп чыгыгыз.

Уңышлар телибез!

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

## I өлеш

**1-10 нчы биремнәргә җаваплар сан, сүз, хәрефләр яисә цифрлар эзлеклелеге рәвешендә языла. Җавапларны иң элек эш текстында языгыз, аннары 1 НЧЕ НОМЕРЛЫ ҖАВАПЛАР БЛАНКЫНА беренче шакмактан башлап <u>бушлык тамгасы, өтер һәм башка төр символларсыз</u> тиешле бирем номерының уң ягына күчерегез. Һәр символны аерым шакмакта бланкта бирелгән үрнәк мисалында языгыз.**

1. Бер Unicode кодировкасында һәр символ 16 бит белән кодлана. Укучы түбәндәге текстны язган (анда артык бушлык тамгалары юк):

«Аю, фил, куян, болан, маймыл, ташбака, крокодил, аллигатор – кыргый хайваннар».

Укучы исемлектән бер хайван исемен сызып ташлаган. Шулай ук ул артык калган өтер һәм бушлык тамгаларын да бетергән, ике бушлык тамгасы рәттән килергә тиеш түгел.

Шушы гамәлләрдән соң яңа җөмләнең әлеге кодировкада үлчәме беренчел җөмлә белән чагыштырганда 16 байтка кимрәк килеп чыккан. Җавапта сызып ташланган хайванның исемен языгыз.

Җавап: ________________________ .

2. Эзтабардан түбәндәге хәбәр алынган:

001001110110100

Әлеге хәбәрдә серсүз – татар хәрефләре эзлеклелеге шифрланган. Серсүздә бары тик Д, А, Ы, Л, К, С хәрефләре генә кулланылган; һәр хәреф түбәндәге таблица буенча икешәрле сүз белән кодланган.

| Д | А | Ы | Л | К | С |
|---|---|---|---|---|---|
| 01 | 100 | 101 | 111 | 00 | 110 |

Шифрны ачып хәбәрне укыгыз. Җавапта серсүзне языгыз.

Җавап: ________________________ .

3. ($x > 16$) ҺӘМ ($x$ так) ТҮГЕЛ

әйтелеше хак булган иң кечкенә $x$ санын языгыз.

Җавап: ________________________ .

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

4. A, B, C, D, E торак пунктлары арасында юллар төзелгән, аларның озынлыгы (километрларда) таблицада китерелгән:

| | A | B | C | D | E |
|---|---|---|---|---|---|
| A | | 1 | 4 | 3 | 7 |
| B | 1 | | 2 | 5 | |
| C | 4 | 2 | | 3 | |
| D | 3 | 5 | 3 | | 2 |
| E | 7 | | | 2 | |

A һәм E пунктлары арасында C пункты аша үтә торган иң кыска юлны ачыклагыз. Бары тик таблицада озынлыклары күрсәтелгән юллар буенча гына хәрәкәтләнергә мөмкин.

Җавап: ________________________ .

5. Альфа исемле башкаручының номерлар сугылган ике командасы бар:

**1. 1 не куш**

**2. *b* га тапкырла**

(b – билгесез натураль сан; b ≥ 2).

Беренче гамәлне башкарганда Альфа экрандагы санны 1 гә арттыра, ә икенчесен башкарганда әлеге санны *b* тапкыр арттыра.

Альфа башкаручысы өчен программа – командаларның номерлары эзлеклелеге.

11211 программасының 6 санының 82 санына үзгәртүе билгеле.

*b* кыйммәтен ачыклагыз.

Җавап: ________________________ .

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

6. Түбәндә биш программалау телендә язылган программа бирелгән.

| Алгоритм теле | Паскаль | Бейсик |
|---|---|---|
| алг<br>башы<br>бөтен s, t<br>кертү s<br>кертү t<br>әгәр s>10 яисә t>10<br>ул вакытта чыгару "YES"<br>башкача чыгару "NO"<br>барлыгы<br>ахыры | var s,t: integer;<br>begin<br>readln(s);<br>readln(t);<br>if (s>10) or (t>10)<br>then<br>writeln("YES")<br>else writeln("NO")<br>end. | DIM s, t AS INTEGER<br>INPUT s<br>INPUT t<br>IF s>10 OR t>10 THEN<br>PRINT 'YES'<br>ELSE<br>PRINT 'NO'<br>ENDIF |

| C++ | Python |
|---|---|
| #include <iostream><br>using namespace std;<br>int main() {<br>int s,t;<br>cin >> s;<br>cin >> t;<br>if (s > 10 \|\| t > 10)<br>cout << "YES";<br>else<br>cout << "NO";<br>return 0;<br>} | s = int(input())<br>t = int(input())<br>if s > 10 or t > 10 :<br>print("YES")<br>else:<br>print("NO") |

Программа 9 тапкыр башкарылган, башкарылганда үзгәрешле кыйммәтләре буларак түбәндәге сан парлары (s, t) кертелгән:

(1, 2); (11, 2); (1, 12); (11, 12); (–11, –12); (–11, 12); (–12, 11); (10, 10); (10, 5).

Нәтиҗәдә «YES» кыйммәте чыгарлык итеп программа ничә мәртәбә башкарылган?

Җавап: ________________________ .

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

7. **obr.org** серверында урнашкан **tat.doc** файлына керү **https** протоколы буенча башкарыла. Файл адресының фрагментлары 1 дән алып 7 гә кадәр хәрефләр кулланып кодланган. Интернет челтәрендәге әлеге файл адресын кодлый торган хәрефләр эзлеклелеген таблицага языгыз.

А) obr.

Б) /

В) org

Г) ://

Д) doc

Е) tat.

Ж) https

Җавап: ________________________ .

8. Эзләү серверының соратулар телендә “ЯИСӘ” логик операциясен тамгалау өчен “|” символы, ә “ҺӘМ” логик операциясен тамгалау өчен “&” символы кулланыла.

Таблицада Интернет челтәренең билгеле бер сегментында соратулар һәм әлеге соратулар буенча табылган битләр саны бирелгән.

| **Сорату** | **Табылган битләр саны (мең)** |
|---|---|
| Балыкчы \| Балык | 780 |
| Балыкчы | 260 |
| Балыкчы & Балык | 50 |

*Балык* соратуы буенча никадәр санда (мең) бит табылыр?

Барлык соратулар бер үк вакытта диярлек башкарылган дип санарга була, шуңа күрә эзләнелә торган сүзләрне үз эченә алган битләр саны соратулар башкару вакытында үзгәрмәгән.

Җавап: ________________________ .

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

9. Рәсемдә А, Б, В, Г, Д, Е, Ж һәм К шәһәрләрен тоташтыручы юллар схемасы бирелгән. Һәр юл буенча бары тик ук белән күрсәтелгән бер юнәлештә генә хәрәкәтләнергә мөмкин. А шәһәреннән К шәһәренә В шәһәре аркылы үтә торган ничә бару юлы бар?




Җавап: ________________________ .

10. Төрле санау системаларында язылган бирелгән өч сан арасыннан иң зурысын табыгыз һәм аны җавапта унарлы санау системасында языгыз. Җавапта бары тик санны гына языгыз, санау системасы нигезен язарга кирәкми.

$23_{16}$, $32_8$, $11110_2$

Җавап: ________________________ .

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

## II өлеш

**Әлеге өлеш биремнәре (11-15) компьютерда башкарылалар. 11 һәм 12 нче биремнәргә җаваплар сүздән яисә саннан гыйбарәт, аларны 1 НЧЕ НОМЕРЛЫ ҖАВАПЛАР БЛАНКЫНА беренче шакмактан башлап бирем номерының уң ягына күчерергә кирәк. Һәр символны аерым шакмакта бланкта бирелгән үрнәк мисалында языгыз.**

**13-15 нче биремнәрне башкару нәтиҗәсе аерым файлдан гыйбарәт (бер бирем өчен – бер файл). Файл форматын, әлеге файл һәм аны саклау өчен каталог исемнәрен Сезгә имтиханны оештыручылар хәбәр итәчәк.**

11. И.С. Тургеневның DEMO-12 каталогы эчендәге Тургенев каталогында урнашкан әсәрләренең берсендә Гнилотёрка елгасы янында барган эпизод искә алына. Операцион системаның эзләү чаралары һәм текст редакторын кулланып әлеге әсәрнең төп героеның фамилиясен ачыклагыз.

Җавап: ________________________ .

12. Проза каталогы эчендәге каталогларда .txt киңәйтелеше белән ничә файл бар? Җавапта бары тик санны гына күрсәтегез.

Җавап: ________________________ .

1-12 нче биремнәргә барлык җавапларны да 1 нче номерлы җаваплар бланкына эш башкару инструкциясе нигезендә күчереп язарга онытмагыз. Һәр җавапның тиңдәш бирем номеры юлында язылган булуын тикшерегез.

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

**Тәкъдим ителгән биремнәрнең берсен сайлап алыгыз: 13.1 яисә 13.2.**

13.1. DEMO-13 каталогында булган мәгълүмат һәм иллюстратив материалны файдаланып “Соры аю” темасына өч слайдтан торган презентация төзегез.

Презентациядә соры аюларның тышкы рәвеше, яшәү тирәлеге һәм яшәү рәвеше турында иллюстрацияле кыска мәгълүматлар булырга тиеш. Барлык слайдлар да бер стильдә булырга, һәр слайдның башламы булырга тиеш.

Имтиханны оештыручылар тәкъдим иткән исем белән презентацияне файлда саклагыз.

Презентацияне төзүгә таләпләр

1. Бит (слайд) параметрлары: экран (16:9), альбом ориентациясе.

2. Слайдның эчтәлеге, төзелеше, андагы шрифт форматы һәм сурәтләрнең урнашулары:

- беренче слайд – презентация исеме язылган титуллы слайд, титуллы слайдның бүлекчә исемендә презентация авторы сыйфатында имтиханда катнашучының идентификацион номеры күрсәтелә;

- икенче слайд – биремдә таләп ителгән төп мәгълүмат, аның үрнәге 2 нче слайд макеты сурәтләнгән рәсемдә бирелгән:

    - слайд исеме;
    - ике текст блогы;
    - ике сурәт;

- өченче слайд – презентация темасы буенча өстәмә мәгълүмат, аның үрнәге 3 нче слайд макеты сурәтләнгән рәсемдә бирелгән:

    - слайд исеме;
    - өч сурәт;
    - өч текст блогы.



Текст блогы мәгълүмат

Презентация темасына төп

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

| | |
|---|---|
| Текст блогы | 3 нче слайд макеты |
| Текст блогы<br>мәгълүмат | Презентация темасына өстәмә |

Текст блогы

Презентациядә бер үк типтагы шрифт кулланылырга тиеш.

Шрифт үлчәмнәре: титуллы слайдта презентация исеме – 40 пункт; титуллы слайдта бүлекчә исеме һәм слайдларның башламнары – 24 пункт; икенче һәм өчен слайдларда бүлекчәләр исемнәре һәм төп текст өчен – 20 пункт.

Текст сурәт өстенә менмәскә һәм фон белән кушылмаска тиеш.

13.2. Текст редакторында документ төзегез һәм әлеге документта үрнәктә бирелгән бизәлешне кабатлап текстны языгыз.

Әлеге текст 14 пункт үлчәмле шрифт белән язылырга тиеш. Төп текст киңлек буенча тигезләнелгән ә абзацның беренче юлы чигенеше 1 см. Текстта калын шрифтлы, курсив һәм ассызылган сүзләр бар.

Текстның киңлеге бит үлчәмнәреннән һәм кырлардан бәйле булу сәбәпле, Сезнең текстның киңлеге үрнәктәгедән аерылырга мөмкин. Бу очракта текстны юлларга бүлү абзацның стандарт киңлегенә тәңгәл килергә тиеш.

Текстны файлда имтиханны оештыручылар тәкъдим иткән исем белән саклагыз.

---

**Углерод** – <u>Меделеев таблицасындагы</u> химик элементларның берсе. Җирдә ирекле рәвештә алмазлар һәм графит рәвешендә очрый, шулай ук киң танылган күп кенә табигый кушылмалар (*углекислоталы газ, известьташ, нефть*) составына керә. Соңгы елларда галимнәр ясалма юл белән углеродның яңа төзелешен (*графен*) алдылар.

| **Матдә** | **Тыгызлык, кг/м$^3$** | **Кабанып китү температурасы, $^0$С** |
|---|---|---|
| Графит | 2100 | 700 |
| Алмаз | 3500 | 1000 |

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

14. Электрон таблицага укучылар үзләре сайлаган предметлар буенча үткәрелгән тест нәтиҗәләре керткәннәр.

| | A | B | C | D |
|---|---|---|---|---|
| 1 | **Төбәк** | **Фамилия** | **Предмет** | **Баллар** |
| 2 | С | 1 нче укучы | Физика | 240 |
| 3 | В | 2 нче укучы | Физкультура | 782 |
| 4 | Ю | 3 нче укучы | Биология | 361 |
| 5 | СВ | 4 нче укучы | Җәмгыять белеме | 377 |

А баганасында укучы укыган төбәк коды; В баганасында – фамилия; С баганасында – укучы сайлаган предмет; D баганасында – тестта җыелган балл язылган.

***Биремне башкарыгыз***

Бирелгән электрон таблицалы файлны ачыгыз (файлның урнашу урынын Сезгә имтиханны оештыручылар әйтерләр). Таблицада бирелгән мәгълүматларга нигезләнеп биремнәрне башкарыгыз.

1. Информатикадан тест үткән ничә укучы 600 дә күбрәк балл җыйганнар. Җавапны таблицаның Н2 шакмагына языгыз.

2. Информатикадан тест үткән укучыларның уртача тест баллын ачыклагыз. Җавапны таблицаның Н3 шакмагына төгәллеге өтердән соң кимендә ике кыйммәт белән языгыз.

3. “В”, “Зел”, “З” кодлы төбәкләрдән катнашучыларның чагыштырмасын тасвирлаган түгәрәк диаграмма төзегез. Диаграмманың өске сул почмагын G6 шакмагы янында урнаштырыгыз.

Килеп чыккан таблицаны имтиханны оештыручылар әйткән исем белән сакларга кирәк.

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

**Тәкъдим ителгән биремнәрнең берсен сайлап алыгыз: 15.1 яисә 15.2.**

15.1. Робот исемле башкаручы яссылыкта сызылган, шакмакларга бүленгән лабиринтта хәрәкәтләнә ала. Күрше (як-ягындагы) шакмаклар арасында стена булуы мөмкин, аның аркылы Робот уза алмый.

Робот 9 команда башкара ала. Биш команда – приказ-командалар.

Аларның дүртесе Роботның хәрәкәте белән идарә итәләр:

**өскә аска сулга уңга**

Әлеге командаларның кайсын да булса башкарганда, Робот бер шакмак алга хәрәкәтләнә: өскә↑, аска↓, сулга←, уңга→. Әгәр Робот стена аркылы хәрәкәт итү командасын алса, ул җимереләчәк.

Шулай ук, Роботның **Буярга** командасы бар, әлеге команданы башкарганнан соң Робот басып торган шакмак буялачак.

Тагын дүрт команда – шартларны тикшерү командалары. Әлеге командалар һәр дүрт юнәлештә юлның ачык булу-булмавын тикшерәләр:

**өскә юл ачык аска юл ачык сулга юл ачык уңга юл ачык**

Әлеге командаларны "**әгәр**" шарты белән бергә файдаланырга мөмкин, аның язылышы түбәндәгечә булырга тиеш:

**әгәр** *шарт* **ул вакытта**
*командалар эзлеклелеге*
**тәмам**

Монда *шарт* – шартны тикшерү командаларының берсе.

*Командалар эзлеклелеге* – бер яисә берничә теләсә кайсы приказ-команда.

Мәсәлән, стена бармы-юкмы икәнен тикшереп уңга хәрәкәтләнү һәм әлеге шакмакны буяу өчен түбәндәге алгоритмнан файдаланырга мөмкин:

**әгәр уңга юл ачык ул вакытта**
**уңга**
**буярга**
**тәмам**

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

***Һәм, яисә, түгел*** логик операторларын кулланып бер шартта берничә шартны тикшерү командасын кулланырга ярый, мәсәлән:

**әгәр (уңга юл ачык) һәм (аска юл ачык түгел) ул вакытта**
**уңга**
**тәмам**

Командалар эзлеклелеген кабатлау өчен “хәзергә” циклын кулланырга мөмкин, аның язылышы түбәндәгечә:

**цб хәзергә** *шарт*
*командалар эзлеклелеге*
**ца**

Мәсәлән, мөмкин кадәр уңга хәрәкәт итү өчен түбәндәге алгоритмнан файдаланырга була:

**цб хәзергә уңга юл ачык**
**уңга**
**ца**

***Биремне башкарыгыз***

Чикләре булмаган кырда горизонталь һәм вертикаль стена бар. Горизонталь стенаның уң як очы вертикаль стенаның югары очы белән тоташкан. **Стеналарның озынлыгы билгеле түгел**. Һәр стенада үтеп чыгу өчен бердәнбер ачыклык бар, аларның урыннары һәм киңлекләрее билгеле түгел. Роботның башлангыч торышы – горионталь стенаның сул очы астындагы шакмакта.

Рәсемдә стеналарның һәм Роботның мөмкин булган урнашу варианты сурәтләнгән (Робот “Р” хәрефе белән күрсәтелгән).




© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

Робот өчен горизонталь стенадан аста һәм вертикаль стенадан сул яктарак терәлеп торган шакмакларны, программаны башкарыр алдыннан Робот урнашкан шакмактан кала, буяу алгоритмын языгыз. Үтеп чыгу өчен ачыклыклар буялмый калырга тиешләр. Робот әлеге шартка туры килгән шакмакларны гына буярга тиеш. Мәсәлән, бирелгән рәсемдә Робот түбәндәге шакмакларны буярга тиеш (рәсемгә кара).



Алгоритм башкарылганда Робот җимерелмәскә, алгоритм башкарылу тәмамланырга тиеш. Роботның соңгы урнашу урыны ирекле була ала.

Алгоритм төрлечә урнашкан стеналар, стенаның төрле урында урнашкан ачыклык һәм төрле киңлектәге ачыклык өчен үтәлергә тиеш.

Алгоритм формаль башкару мохитендә башкарылырга яисә текст редакторында язылырга мөмкин.

Алгоритмны текст файлында саклагыз. Файл һәм каталог исемен Сезгә имтиханны оештыручылар хәбәр итәчәк.

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

15.2. Натураль саннар эзлеклелегендә 4 кә кабатлы, әмма 7 гә кабатлы булмаган саннар санын ачыклый торган программа төзегез. Программага иң элек эзлеклелектәге саннар саны, аннары саннар үзләре кертеләләр. Эзлеклелектә һәрвакыт 4 кә кабатлы һәм 7 гә кабатлы булмаган сан була.

Саннар саны 1000 нән артып китми. Кертелгән саннар 30000 нән зур түгел.

Нәтиҗәдә программа 4 кә кабатлы, әмма 7 гә кабатлы булмаган саннар санын хәбәр итәргә тиеш.

**Программа эшенә мисал:**

| Кертелә торган мәгълүмат | Нәтиҗәдәге мәгълүмат |
|---|---|
| 4<br>16<br>28<br>26<br>24 | 2 |

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

## Информатикадан имтихан эшен бәяләү системасы

### I өлеш

1 нче өлешнең һәр дөрес башкарылган биреме һәм 2 нче өлешнең 11 нче һәм 12 нче дөрес башкарлыган биремнәре 1 балл белән бәяләнәләр. Имтихан тотучы дөрес җавап эталонына туры килгән җавап бирсә, 1 нче өлеш биреме дөрес үтәлгән дип санала.

**Биремнәрнең җаваплары**

| Бирем номеры | Дөрес җавап |
|---|---|
| 1 | МАЙМЫЛ |
| 2 | КАЛДЫК |
| 3 | 18 |
| 4 | 8 |
| 5 | 10 |
| 6 | 5 |
| 7 | 7413265 |
| 8 | 570 |
| 9 | 10 |
| 10 | 35 |
| 11 | ОВСЯНИКОВ |
| 12 | 16 |

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

## 2 нче өлеш

## Киңәйтелгән җаваплы биремнәрне бәяләү критерийлары

13.1. DEMO-13 каталогында булган мәгълүмат һәм иллюстратив материалны файдаланып “Соры аю” темасына өч слайдтан торган презентация төзегез.

Презентациядә соры аюларның тышкы рәвеше, яшәү тирәлеге һәм яшәү рәвеше турында иллюстрацияле кыска мәгълүматлар булырга тиеш. Барлык слайдлар да бер стильдә булырга, һәр слайдның башламы булырга тиеш.

Имтиханны оештыручылар тәкъдим иткән исем белән презентацияне файлда саклагыз.

Презентацияне төзүгә таләпләр

1. Бит (слайд) параметрлары: экран (16:9), альбом ориентациясе.

2. Слайдның эчтәлеге, төзелеше, андагы шрифт форматы һәм сурәтләрнең урнашулары:

- беренче слайд – презентация исеме язылган титуллы слайд, титуллы слайдның бүлекчә исемендә презентация авторы сыйфатында имтиханда катнашучының идентификацион номеры күрсәтелә;

- икенче слайд – биремдә таләп ителгән төп мәгълүмат, аның үрнәге 2 нче слайд макеты сурәтләнгән рәсемдә бирелгән:

    - слайд исеме;

    - ике текст блогы;

    - ике сурәт;

- өченче слайд – презентация темасы буенча өстәмә мәгълүмат, аның үрнәге 3 нче слайд макеты сурәтләнгән рәсемдә бирелгән:

    - слайд исеме;

    - өч сурәт;

    - өч текст блогы.

| | |
|---|---|
| Презентация исеме<br>Автор турында мәгълүмат | 1 нче слайд макеты<br>Презентация темасы |

| | |
|---|---|
| Текст блогы | 2 нче слайд макеты |
| Текст блогы мәгълүмат | Презентация темасына төп |

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

| | |
|---|---|
| Текст блогы | 3 нче слайд макеты |
| Текст блогы мәгълүмат | Презентация темасына өстәмә |

Текст блогы

Презентациядә бер үк типтагы шрифт кулланылырга тиеш.

Шрифт үлчәмнәре: титуллы слайдта презентация исеме – 40 пункт; титуллы слайдта бүлекчә исеме һәм слайдларның башламнары – 24 пункт; икенче һәм өчен слайдларда бүлекчәләр исемнәре һәм төп текст өчен – 20 пункт.

Текст сурәт өстенә менмәскә һәм фон белән кушылмаска тиеш.

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү өчен күрсәтмәләр** (җавапның башка формулировкалары мөмкин, әмма мәгънә үзгәрешсез булырга тиеш) | | |
|---|---|---|
| Бирелгән үрнәккә тәңгәл килгән текст дөрес җавап булып санала | | |
| **Бәяләү өчен күрсәтмәләр** | | **Баллар** |
| Бирелгән тема буенча өч слайдтан торган, төзелеше, эчтәлеге һәм формасы буенча бирем шартларына туры килгән презентация тәкъдим ителгән. | | 2 |
| **Төзелеше** | Презентация өч слайдтан тора.<br>Слайдларда мәгълүмат тиңдәш слайд макетында сурәтләнгән үрнәк буенча урнаштырылган.<br>Презентациянең титуллы слайдка чыгарылган исеме бар.<br>2 нче һәм 3 нче слайдларның презентация темасына һәм эчтәлегенә җавап бирүче башламнары бар.<br>Сурәтләр һәм текст тулаем алганда презентация темасына һәм һәр конкрет слайд эчтәлегенә туры киләләр.<br>Текст мәсьәлә шартында бирелгән текст файлыннан алынган яисә презентация темасына туры китереп автор тарафыннан уйлап чыгарып язылган булырга мөмкин. | |
| **Шрифт** | Презентациядә бер типтагы шрифт кулланыла. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Шрифт үлчәмнәре: титуллы слайдта презентация исеме – 40 пункт; титуллы слайдта бүлекчә исеме һәм слайдларның башламнары – 24 пункт; икенче һәм өчен слайдларда бүлекчәләр исемнәре һәм төп текст өчен – 20 пункт. | | |

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

| | | |
|---|---|---|
| | Текст сурәт өстенә менмәгән һәм фон белән кушылмаган. | |
| **Сурәтләр** | Сурәтләр слайдларда бирем шартларына туры китереп урнаштырылганнар, слайд эчтәлегенә туры киләләр. | |
| Бирелгән тема буенча өч слайдтан торган презентация тәкъдим ителгән, анда таләп ителгән шартларның берсе: төзелеше, шрифтны сайлау яисә сурәтләрне тиешенчә урнаштыру үтәлмәгән<br>ЯИСӘ<br>бирелгән тема буенча ике слайдтан торган презентация тәкъдим ителгән, аның төзелеше, шрифтны сайлау яисә сурәтләр урнаштыру ягыннан җитешсезлекләре юк. | | 1 |
| 1 яисә 2 балл алырлык критерийларга туры килү өчен шартлар үтәлмәгән. | | 0 |
| | *Максималь балл* | 2 |

13.2. Текст редакторында документ төзегез һәм әлеге документта үрнәктә бирелгән бизәлешне кабатлап текстны языгыз.

Әлеге текст 14 пункт үлчәмле шрифт белән язылырга тиеш. Төп текст киңлек буенча тигезләнелгән ә абзацның беренче юлы чигенеше 1 см. Текстта калын шрифтлы, курсив һәм ассызылган сүзләр бар.

Текстның киңлеге бит үлчәмнәреннән һәм кырлардан бәйле булу сәбәпле, Сезнең текстның киңлеге үрнәктәгедән аерылырга мөмкин. Бу очракта текстны юлларга бүлү абзацның стандарт киңлегенә тәңгәл килергә тиеш.

Текстны файлда имтиханны оештыручылар тәкъдим иткән исем белән саклагыз. ___________________

**Углерод** – <u>Меделеев таблицасындагы</u> химик элементларның берсе. Җирдә ирекле рәвештә алмазлар һәм графит рәвешендә очрый, шулай ук киң танылган күп кенә табигый кушылмалар (*углекислоталы газ, известьташ, нефть*) составына керә. Соңгы елларда галимнәр ясалма юл белән углеродның яңа төзелешен (*графен*) алдылар.

| **Матдә** | **Тыгызлык, кг/м$^3$** | **Кабанып китү температурасы, $^0$C** |
|---|---|---|
| Графит | 2100 | 700 |
| Алмаз | 3500 | 1000 |

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

| Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү өчен күрсәтмәләр (җавапның башка формулировкалары мөмкин, әмма мәгънә үзгәрешсез булырга тиеш) | |
|---|---|
| Бирелгән үрнәккә тәңгәл килгән текст дөрес җавап булып санала | |
| **Бәяләү өчен күрсәтмәләр** | **Баллар** |
| Бирем дөрес башкарылган. Биремнең үтәлешен тикшергәндә түбәндәге элементларның башкарылуы контрольдә тотыла.<br>1. Төп текст 14 пункт үлчәмле туры нормаль шрифт белән җыелган.<br>2. Абзацта текст киңлек буенча тигезләнгән.<br>3. Абзац чигенеше (1 см) дөрес куелган, абзац чигенешен ясау өчен бушлык тамгаларын кулланырга ярамый.<br>4. Текст тулаем алганда дөрес һәм хатасыз язылган (берничә ялгыш басылу (опечатка) рөхсәт ителә).<br>5. Текстта яңа юлга күчү өчен юлларны өзү кулланылмый (текстны юлдан юлга күчерү текст редакторы тарафыннан башкарыла).<br>6. Төп текстта барлык тиешле сүзләр калын, курсив яисә ассызылган шрифт белән аерымланган.<br>7. Таблицада юллар һәм баганалар саны тиешле санда.<br>8. «м$^3$» һәм «°С» тамгаланышларында югары индекста «3» һәм «0» цифрлары яисә «о» хәрефе (яисә B316 белән B016 кодлы махсус символлар) кулланыла.<br>Шул ук вакытта текстта күп дигәндә биш орфографик (пунктуацион) хата яисә ялгыш язылыш, шулай ук сүзләр арасында бушлык тамгаларын, тыныш билгеләрен һ.б. куюда хаталар рөхсәт ителә.<br>Текст күп дигәндә түбәндә бирелгән хаталарның берсен үз эченә алырга мөмкин.<br>1. Үлчәме дөрес булмаган шрифт кулланыла.<br>2. Үрнәктә бирелгән сүзләрнең берсе калын, курсив яисә ассызылган түгел.<br>3. «м$^3$» һәм «°С» тамгаланышларын язу өчен югары индекс яисә махсус символ кулланылмаган.<br>4. Төп абзацта шрифт киңлек буенча тигезләнмәгән.<br>5. Абзацның беренче юлында абзац чигенеше юк. | 2 |

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

| | |
|---|---|
| Өстә әйтеп үтелгән хаталар саны ике яисә өч (бер типтагы хаталар бер хата дип исәпләнелә), яисә түбәндәге хаталарның берсе бар.<br>1. Таблица юк, яисә таблицаның юллары һәм баганалары саны дөрес түгел.<br>2. Төп текст курсив яисә калын шрифт белән җыелган.<br>3. Текстны юлдан юлга күчерү өчен юлларны өзү яисә абзац ахыры символы кулланылган.<br>4. Абзац чигенеше бушлык тамгалары ярдәмендә ясалган.<br>Текстта күп дигәндә 10 орфографик (пунктуацион) хата, ялгыш язылыш, бушлык тамгаларын урнаштыруда хата ясау рөхсәт ителә.<br>Бирем тулысынча диярлек эшләнгән, әмма бирелгән үрнәк белән нык аерылган очракта, мәсәлән таблица белән текст арасында зур вертикаль интервал бар, таблицада юлларның биеклекләре артык зур. | 1 |
| Бирем хаталы эшләнгән, яисә 2 балл алу өчен санап үтелгән критерийларда дүрттән артык хата бар, яисә 1 балл алу өчен санап үтелгән критерийлар буенча ким дигәндә ике хата бар. | 0 |
| *Максималь балл* | 2 |

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

14. Электрон таблицага укучылар үзләре сайлаган предметлар буенча үткәрелгән тест нәтиҗәләре кертәннәр.

| | A | B | C | D |
|---|---|---|---|---|
| 1 | **Төбәк** | **Фамилия** | **Предмет** | **Баллар** |
| 2 | С | 1 нче укучы | Физика | 240 |
| 3 | В | 2 нче укучы | Физкультура | 782 |
| 4 | Ю | 3 нче укучы | Биология | 361 |
| 5 | СВ | 4 нче укучы | Җәмгыять белеме | 377 |

А баганасында укучы укыган төбәк коды; В баганасында – фамилия; С баганасында – укучы сайлаган предмет; D баганасында – тестта җыелган балл язылган.

***Биремне башкарыгыз***

Бирелгән электрон таблицалы файлны ачыгыз (файлның урнашу урынын Сезгә имтиханны оештыручылар әйтерләр). Таблицада бирелгән мәгълүматларга нигезләнеп биремнәрне башкарыгыз.

1. Информатикадан тест үткән ничә укучы 600 дә күбрәк балл җыйганнар. Җавапны таблицаның Н2 шакмагына языгыз.

2. Информатикадан тест үткән укучыларның уртача тест баллын ачыклагыз. Җавапны таблицаның Н3 шакмагына төгәллеге өтердән соң кимендә ике кыйммәт белән языгыз.

3. “В”, “Зел”, “З” кодлы төбәкләрдән катнашучыларның чагыштырмасын тасвирлаган түгәрәк диаграмма төзегез. Диаграмманың өске сул почмагын G6 шакмагы янында урнаштырыгыз.

Килеп чыккан таблицаны имтиханны оештыручылар әйткән исем белән сакларга кирәк.

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү өчен күрсәтмәләр**<br>(җавапның башка формулировкалары мөмкин, әмма мәгънә үзгәрешсез булырга тиеш) |
|---|
| **OpenOffice.org Calc һәм для Microsoft Excel өчен чишелеш**<br>Биремне чишүнең ысуллары күп төрле. Түбәндә мөмкин булган чишү юлларының берсе китерелгән.<br><br>Әзерлек өлеше.<br>E2 шакмагына<br>=ЕСЛИ(И(C2="информатика"; D2>600); 1;0))<br>яисә<br>=IF(AND(C2="информатика"; D2>600); 1;0)<br>формуласын язабыз.<br>(Биредә һәм аннары беренче формула рус телле интерфейс, икенчесе – инглиз телле интерфейс өчен кулланыла.)<br>F2 шакмагына<br>=ЕСЛИ(C2="информатика"; D2; 0)<br>яисә<br>=IF(C2="информатика"; D2; 0)<br>формуласын язабыз.<br><br>Әлеге формулаларны E3:F1001 диапазонындагы барлык шакмакларга күчереп язйык.<br><br>1 нче бирем.<br>H2 шакмагына<br>=СУММ(E2:E1001)<br>яисә<br>=SUM(E2:E1001)<br>формуласын язабыз.<br><br>2 нче бирем.<br>I2 шакмагына<br>=СЧЁТЕСЛИ(F2:F1001; ">0")<br>яисә<br>=COUNTIF(F2:F1001; ">0")<br>формуласын язабыз.<br>I3 шакмагына<br>=СУММ(F2:F1001)<br>яисә<br>=SUM(F2:F1001)<br>формуласын язабыз. |

| |
|---|
| H3 шакмагына<br>=I3/I2<br>формуласын язабыз.<br><br>Башка төр чишү вариантлары да булырга мөмкин.<br>Мәсәлән, 1 нче биремне үтәгәндә мәгълүматларны кирәкле юллар рәттән торырлык итеп тәртипләштерергә мөмкин, ә аннары аларның санын юллар нумерациясен кулланып исәпләп чыгарырга була. |

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте



Әгәр бирем дөрес башкарылган булса һәм биремне башкарганда әлеге биремне тикшерү өчен махсус әзерләнгән файллар кулланылса, ул вакытта түбәндәге җаваплар килеп чыгарга тиеш:

Беренче сорауга: 32.
Икенче сорауга: 546,82.
Өченче биремгә:




Диаграмма секторлары 132:29:108 нисбәтенә визуаль туры килергә тиеш. Секторларның урнашу эзлеклеге төрле булырга мөмкин.

| Бәяләү өчен күрсәтмәләр | Баллар |
|---|---|
| Алынган җаваплар дөрес булса, барлык очракларда да җавапны башка шакмакларга язу рөхсәт ителә (биремдә күрсәтелгәннәрдән тыш). | |
| Ике сорауга дөрес җавап алынган һәм диаграмма дөрес төзелгән | 3 |
| 3 балл кую өчен шартлар үтәлмәгән. Түбәндәге ситуацияләрнең берсе булуы ихтимал:<br>- ике сорауның берсенә генә дөрес җавап алынган, диаграмма дөрес төзелгән; | 2 |

| | |
|---|---|
| - ике сорауга да дөрес җавап алынган, диаграмма дөрес төзелмәгән. | |
| 2 балл кую өчен шартлар үтәлмәгән. Түбәндәге ситуацияләрнең берсе булуы ихтимал:<br>- ике сорауның берсенә генә дөрес җавап алынган;<br>- диаграмма дөрес төзелгән. | 1 |
| 1, 2 яисә 3 балл кую өчен шартлар үтәлмәгән. | 0 |
| *Максималь балл* | 3 |

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

15.1. Робот исемле башкаручы яссылыкта сызылган, шакмакларга бүленгән лабиринтта хәрәкәтләнә ала. Күрше (як-ягындагы) шакмаклар арасында стена булуы мөмкин, аның аркылы Робот уза алмый.

Робот 9 команда башкара ала. Биш команда – приказ-командалар.

Аларның дүртесе Роботның хәрәкәте белән идарә итәләр:

**өскә аска сулга уңга**

Әлеге командаларның кайсын да булса башкарганда, Робот бер шакмак алга хәрәкәтләнә: өскә↑, аска↓, сулга←, уңга→. Әгәр Робот стена аркылы хәрәкәт итү командасын алса, ул җимереләчәк.

Шулай ук, Роботның **Буярга** командасы бар, әлеге команданы башкарганнан соң Робот басып торган шакмак буялачак.

Тагын дүрт команда – шартларны тикшерү командалары. Әлеге командалар һәр дүрт юнәлештә юлның ачык булу-булмавын тикшерәләр:

**өскә юл ачык аска юл ачык сулга юл ачык уңга юл ачык**

Әлеге командаларны "**әгәр**" шарты белән бергә файдаланырга мөмкин, аның язылышы түбәндәгечә булырга тиеш:

**әгәр** *шарт* **ул вакытта**
*командалар эзлеклелеге*
**тәмам**

Монда *шарт* – шартны тикшерү командаларының берсе.

*Командалар эзлеклелеге* – бер яисә берничә теләсә кайсы приказ-команда.

Мәсәлән, стена бармы-юкмы икәнен тикшереп уңга хәрәкәтләнү һәм әлеге шакмакны буяу өчен түбәндәге алгоритмнан файдаланырга мөмкин:

**әгәр уңга юл ачык ул вакытта**
**уңга**
**буярга**
**тәмам**

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

***Һәм, яисә, түгел*** логик операторларын кулланып бер шартта берничә шартны тикшерү командасын кулланырга ярый, мәсәлән:

**әгәр (уңга юл ачык) һәм (аска юл ачык түгел) ул вакытта**
**уңга**
**тәмам**

Командалар эзлеклелеген кабатлау өчен “хәзергә” циклын кулланырга мөмкин, аның язылышы түбәндәгечә:

**цб хәзергә** *шарт*
*командалар эзлеклелеге*
**ца**

Мәсәлән, мөмкин кадәр уңга хәрәкәт итү өчен түбәндәге алгоритмнан файдаланырга була:

**цб хәзергә уңга юл ачык**
**уңга**
**ца**

***Биремне башкарыгыз***

Чикләре булмаган кырда горизонталь һәм вертикаль стена бар. Горизонталь стенаның уң як очы вертикаль стенаның югары очы белән тоташкан. **Стеналарның озынлыгы билгеле түгел.** Һәр стенада үтеп чыгу өчен бердәнбер ачыклык бар, аларның урыннары һәм киңлекләрее билгеле түгел. Роботның башлангыч торышы – гориontaль стенаның сул очы астындагы шакмакта.

Рәсемдә стеналарның һәм Роботның мөмкин булган урнашу варианты сурәтләнгән (Робот “Р” хәрефе белән күрсәтелгән).




© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

Робот өчен горизонталь стенадан аста һәм вертикаль стенадан сул яктарак терәлеп торган шакмакларны, программаны башкарыр алдыннан Робот урнашкан шакмактан кала, буяу алгоритмын языгыз. Үтеп чыгу өчен ачыклыклар буялмый калырга тиешләр. Робот әлеге шартка туры килгән шакмакларны гына буярга тиеш. Мәсәлән, бирелгән рәсемдә Робот түбәндәге шакмакларны буярга тиеш (рәсемгә кара).



Алгоритм башкарылганда Робот җимерелмәскә, алгоритм башкарылу тәмамланырга тиеш. Роботның соңгы урнашу урыны ирекле була ала.

Алгоритм төрлечә урнашкан стеналар, стенаның төрле урында урнашкан ачыклык һәм төрле киңлектәге ачыклык өчен үтәлергә тиеш.

Алгоритм формаль башкару мохитендә башкарылырга яисә текст редакторында язылырга мөмкин.

Алгоритмны текст файлында саклагыз. Файл һәм каталог исемен Сезгә имтиханны оештыручылар хәбәр итәчәк.

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү өчен күрсәтмәләр**<br>(җавапның башка формулировкалары мөмкин, әмма мәгънә үзгәрешсез булырга тиеш) |
|---|
| Башкаручы командаларын калын шрифт белән, ә алгоритмга аңлатма биргән һәм аның бер өлеше булмаган комментарийларны – курсив белән языйк. Комментарий башлануын «\|» символы белән тамгаларбыз.<br>\| *Робот басып торган шакмакны үткәреп җибәрәбез.*<br>**уңга**<br>\| *Горизонталь стенадагы аралыкка барып җиткәнче уңга таба хәрәкәт итәбез.*<br>\| *Узган шакмакларны буйыйбыз.*<br>**цб хәзергә өстә түгел ачык**<br>    **буярга**<br>    **уңга**<br>**ца**<br>\| *Горизонталь стенага кадәр алга таба хәрәкәт итәбез.*<br>**цб хәзергә өстә ачык**<br>    **уңга**<br>**ца**<br>\| *Вертикаль стенага барып җиткәнче уңга таба хәрәкәт итәбез.*<br>\| *Узган шакмакларны буйыйбыз.*<br>**цб хәзергә унда ачык**<br>    **буярга**<br>    **уңга**<br>**ца**<br>\| *Вертикаль стенадагы аралыкка барып җиткәнче аска таба хәрәкәт итәбез.*<br>\| *Узган шакмакларны буйыйбыз.*<br>**цб хәзергә унда түгел ачык**<br>    **буярга**<br>    **аска**<br>**ца**<br>\| *Вертикаль стеанага кадәр алга таба хәрәкәт итәбез.*<br>**цб хәзергә унда ачык**<br>    **аска**<br>**ца**<br>\| *Вертикаль стена чигенә кадәр аска таба хәрәкәт итәбез.*<br>\| *Узган шакмакларны буйыйбыз.*<br>**цб хәзергә унда түгел ачык**<br>    **буярга**<br>    **аска**<br>**ца**<br>Башка чишелеш вариантлары да булырга мөмкин. |

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

| Бәяләү өчен күрсәтмәләр | Баллар |
|---|---|
| Алгоритм барлык башлангыч кыйммәтләр өчен дөрес башкарыла. | 2 |
| Барлык башлангыч кыйммәтләр өчен түбәндәгеләр хак:<br>1) алгорит тәмамлана һәм Робот җимерелми;<br>2) буялган шакмаклар саны 10 нан артык түгел;<br>3) буялырга тиеш булган шакмакларның 10 нан кимрәге буялмый калды. | 1 |
| Бирем дөрес башкарылмаган, ягъни 1 яисә 2 балл кую өчен шартлар үтәлмәгән. | 0 |
| *Максималь балл* | 2 |

15.2. Натураль саннар эзлеклелегендә 4 кә кабатлы, әмма 7 гә кабатлы булмаган саннар санын ачыклый торган программа төзегез. Программага иң элек эзлеклелектәге саннар саны, аннары саннар үзләре кертеләләр. Эзлеклелектә һәрвакыт 4 кә кабатлы һәм 7 гә кабатлы булмаган сан була.

Саннар саны 1000 нән артып китми. Кертелгән саннар 30000 нән зур түгел.

Нәтиҗәдә программа 4 кә кабатлы, әмма 7 гә кабатлы булмаган саннар санын хәбәр итәргә тиеш.

**Программа эшенә мисал:**

| Кертелә торган мәгълүмат | Нәтиҗәдәге мәгълүмат |
|---|---|
| 4<br>16<br>28<br>26<br>24 | 2 |

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

**Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү өчен күрсәтмәләр**
(җавапның башка формулировкалары мөмкин, әмма мәгънә үзгәрешсез булырга тиеш)

Теләсә кайсы программалау телендә язылган программа мәсьәләнең чишелеше була ала. Паскаль телендә язылган дөрес чишелеш үрнәге:

```
var n,i,a,k: integer;
begin
 readln(n);
 k := 0;
 for i := 1 to n do
 begin
  readln(a);
  if (a mod 4 = 0) and (a mod 7 <> 0) then k:=k+1;
 end;
 writeln(k)
end.
```

Башка чишелеш вариантлары да булырга мөмкин.
Программа эшенең дөреслеген тикшерү өчен түбәндәге тестларны кулланырга кирәк:

| № | Кертелә торган мәгълүмат | Нәтиҗәдәге мәгълүмат |
|---|---|---|
| 1 | 3<br>4<br>7<br>28 | 1 |
| 2 | 4<br>28<br>16<br>4<br>24 | 3 |
| 3 | 5<br>24<br>28<br>4<br>44<br>2 | 3 |

| Бәяләү өчен күрсәтмәләр | Баллар |
|---|---|
| Дөрес чишелеш тәкъдим ителгән. Барлык тестлар өчен дә программа дөрес эшли. | 2 |

| | |
|---|---|
| Программа теләсә кайсы прогограммалау телендә язылган булырга мөмкин. | |
| Программа өстә бирелгән тестларның берсендә дөрес нәтиҗә бирми. Мәсәлән, саннарны сайлап алу шарты хаталы язылган чишелеш (a mod 10 = 4) 2 нче тестта ялгыш нәтиҗә чыгарачак. | 1 |
| Программа тестларның һәрберсендә ялгыш нәтиҗә бирә. | 0 |
| *Максималь балл* | 2 |

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

Төп гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибе (Россия Мәгариф министрлыгының 2018 елның 7 ноябрендәге 189/1513 нче номерлы карары, Россия Юстиция министрлыгы тарафыннан 2018 елның 10 декабрендә 52953 нче номер белән теркәлгән) буенча

“64. Имтихан эшләре ике эксперт тарафыннан тикшерелә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча бер-берсеннән бәйсез рәвештә экспертлар имтихан эше биремнәренең һәр биреме җавабына баллар куялар... Экспертлар куйган баллар бер-берсеннән нык аерылган очракта өченче тикшерү билгеләнә. Баллар нык аерылу шул уку предметын бәяләү критерийлары белән билгеләнгән.

Өченче эксперт предмет комиссиясе рәисе тарафыннан имтихан эшен элек тикшермәгән экспертлар арасыннан сайлап алып билгеләнә.

Өченче экспертка имтихан эшләрен алдагы экспертлар куйган баллар турында мәгълүмат бирелә. Өченче эксперт куйган баллар ахыр нәтиҗә баллар булып санала”.

Ике эксперт куйган баллар нык аерыла дип 13-15 нче биремнәрнең берәрсендә аларның аермасы 2 яисә күбрәк балл булганда санала. *Өченче эксперт бары тик шундый нык аерылган биремнәрнең җавапларын гына тикшерә.*

© 2020 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте